| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЕРЫКЛИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗИРЕКЛЕ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2025 г. с.Ерыкла № 6

**«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлегендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2022 елның 4 мартындагы 8 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, «Республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында»2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Башкарма комитетының 4.03.2022 ел, № 8 `карары белән расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлегендә белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

- 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4.1 пунктчасын өстәргә:

«4.1) мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ белешмәләре бирелгән очракта, федераль башкарма хакимият органнары, дәүләт бюджеттан тыш фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектларының башкарма органнары, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы аша мондый затның яисә мондый затның шәхси белешмәләр эшкәртүгә законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда ризалыгын алу таләп ителми;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Зирекле авыл җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **А.Р.Зиннәтуллин**